РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.06.2019 № 648-п

Муниципаль районда гамәлгә ашырыла
торган муниципаль контроль төрләре
исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен раслау турында» 22.05.2010 ел, 509-п номерлы карары нигезендә, 2019 елга «Россия Федерациясе субъектларында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен кабул итүгә бәйле рәвештә (РФ Хөкүмәтенең 19.04.2010 ел, 783-р номерлы боерыгы белән расланган), шулай ук Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең Комплекслы планының 159 пунктын («Муниципаль контроль органнарының эш методлары өлешендә муниципаль контрольне камилләштерү буенча чараларны («юл карталарын) актуальләштерү») үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль районда гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга (теркәлә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – икътисад бүлеге начальнигы М.М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

РАСЛАНДЫ:
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
«___» ___ 2019 ел ____ номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы**
**Саба муниципаль районында гамәлгә ашырыла торган**
**муниципаль контроль төрләре исемлеге**

1. Авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.